ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» 10 2024 ел № 288

«Капиталь төзелеш объектыннан яисә җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү» проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район башлыгы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге халкы катнашында «Капиталь төзелеш объектыннан яисә җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү» проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары Б.Р. Газизуллин;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты юридик бүлек мөдире Р.С.Фатыхов.
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Ю.М. Перфилов;
- кадастр номеры 16:12:130101:249 булган җир кишәрлеге милекчесе Терентьев А.В.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру белән кызыксынучы затларга хәбәр итү вакытыннан башлап гавами тыңлауларның йомгаклары турында нәтиҗәләр басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артык вакыт узарга тиеш түгел.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль район
башлыгы

Р. Р. Нотфуллин